ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2022 г. Заинск № 505

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү, мондый категориядәге гражданнарның социаль якланганлык дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрү максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 кушымтада түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.1.6 пунктына “хәрби хезмәт узучы һәм махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләнгән гражданнарның балалары» дигән сүзләрне өстәргә;

1.2. Түләүсез туклану бирү тәртибе 5 бүлегенең 5.2. пунктына түбәндәге эчтәлектәге бишенче абзацны өстәргә:

«-хәрби хезмәт узучы һәм махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләнгән гражданнарның балалары (Зәй шәһәре һәм Зәй районы Хәрби комиссариаты тарафыннан бирелгән исемлекләр нигезендә)»;

1.3. Түләүсез туклану бирү тәртибе 5 бүлегенең 5.2. пунктына түбәндәге эчтәлектәге унберенче абзацны өстәргә:

**«-хәрби хезмәт узучы һәм махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләнгән гражданнарның балалары:**
- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язмача гариза;
- хәрби комиссариаттан белешмә».

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 кушымтада «полиция хезмәткәрләренең балалары» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге хезмәткәрләре балалары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм, 2022 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган 2 пункттан тыш, 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42